Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXXII-12**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 24 июле

2017 елда һәм 2018 елның беренче яртыеллыгында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Балык Бистәсе муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе Р. А. Сираевның 2017 елда һәм 2018 елның беренче яртыеллыгында Татарстан Республикасында Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында мәгълүматын тыңлап тикшергәннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елда һәм 2018 елның беренче яртыеллыгында Татарстан Республикасында Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен үтәү турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Балык Бистәсе муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесенә аның вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм итәргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына, оештыру-хокукый формаларына һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, учреждениеләргә, оешмаларга, предприятиеләргә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Балык Бистәсе муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесенә аның вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда булышырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов